Исполнительный комитет
Тихоновского сельского поселения
Менделеевского муниципального района
Республики Татарстан
423655 Менделеевский район
с.Тихоново ул. Шишкина д.3а

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Тихоново авыл жирлеге
башкарма комитеты
423655 Менделеевск районы
Тихоново авылы Шишкин урамы 3а

тел./факс 8 (85549) 3-43-62, E-mail: Tihon.Men@tatar.ru

16 июль 2025 ел № 5

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

Хөкем ителүчеләргә мәҗбүри эшләр
рәвешендә җәзасын үтәү урынын
билгеләү турында

Россия Федерациясе Җинаять-үтәтү кодексының 25 һәм 28 статьялары нигезендә, мәҗбүри эшләр рәвешендә җинаять җәзасы үтәлешен тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлеге территориясендә хөкем ителгәннәр өчен мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәү урыннарын 1 нче кушымта нигезендә билгеләргә.

2. “Хөкем ителгәннәр өчен мәҗбүри һәм төзәтү эшләре рәвешендә җәза үтәү урыннарын билгеләү турында” Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 16 нчы мартындагы 1 нче номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында «Норматив документлар» бүлегендә урнаштырырга һәм www.mendeleevsk.tatar.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http//pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Тихоново авыл җирлеге башкарма комитеты
җитәкчесе вазифаларын башкаручы А.Г. Гараева

Килештерелгән:
"Россия Федераль җәзаларны үтәтү хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсе җинаять-башкарма инспекциясе" Федераль казна учреждениесенең Менделеевск муниципальара филиалы башлыгы
А.Н. Сутягин

Килештерелгән:
"Россия Федераль җәзаларны үтәтү хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсе җинаять-башкарма инспекциясе" Федераль казна учреждениесенең Менделеевск муниципальара филиалы башлыгы
_______________2025 ел
А.Н. Сутягин

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлеге Башкарма комитетының 2025 елның 16 июлендәге 5 нче номерлы карарына 1 кушымта

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлеге территориясендә хөкем ителүчеләргә мәҗбүри эшләр рәвешендә җәзасын үтәү урыннары исемлеге

| № п/п | Оешма исеме | Адрес | Виды работ |
|---|---|---|---|
| 1. | Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлеге Башкарма комитеты | Татарстан Республикасы Менделеевск районы Тихоново авылы, Шишкин урамы, 3а йорты | Территорияне җыештыру: чүп-чар җыю, төяү һәм бушату, печән чабу, агач һәм куакларны кисү, кар чистарту, бозларны җыештыру, су скважинасында һәм биологик чистарту корылмаларында ремонт эшләре, йорт яны территорияләрен һәм урман утырту полосалары юлларын төзекләндерү, җир эшләре. |